СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

26 ФЕВРАЛЬ, 1997ел. ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 22 (8034) | Бәясе билгеләнгәнчә.

## Якты Күлдә - яңа мәктәп

Якты Күл авылы халкы яңа мәктәп ачылуны көтеп алды. Ниһаять, узган якшәмбедә авылда бу вакыйгага багышланган тантана булып узды. Анда авылның яше - карты җыелган иде, Норлаттан һәм тирә - күрше авыллардан кунаклар да килде.

- Мәктәп ачылуга шатбыз - бу фикер тантанада чыгыш ясаган ата - аналар, укучылар чыгышларында кызыл җеп булып сузылды. Якты Күл ассоциациясе рәисе В.В.Сатдаров, Яңа Иглай җирле үзидарә Советы рәисе В.Ш.Рәҗәпов та, чыгыш ясаучыларның фикерләрен куәтләп, авылның мәктәп, балалар белән ямьле булуын билгеләп, укучыларны яхшы укырга, чын кеше булып үсәргә чакырдылар. Тантанада чыгыш ясаган район хакимияте башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногъманова һәм район мәгариф бүлеге мөдире Н.Х.Абдуллин Якты Күл авылы халкын, барлык укучыларны яңа, унайлыклы мәктәпле булулары белән кайнар котладылар һәм уңышлар теләделәр.

# КИЧӘ. БҮГЕН. ИРТӘГӘ.

### Ватанны саклаучылар көненә багышлап

## ҖИРДӘ ТЫНЫЧЛЫК ХАКЫНА

Ватанны саклаучылар көне алдыннан район мәдәният йортында үткән кичә шулай дип аталды. 23 февраль - календарьдагы коры дата гына түгел: илебездә идея кыйммәтләре үзгәрүгә дә карамастан, бу бәйрәмне халык хәтереннән юып ташлап булмый. Шуңа да мәдәният йортында үткән театральләштерелгән тамашаны куючылар бәйрәм атмосферасы булдыру гына түгел, яшьләрдә патриотизм хисен уятуны да максат иткәннәр иде. Һәм, мин әйтер идем, алар үз дигәннәренә ирештеләр дә.

Мәдәният йорты фойесында тамашага кадәр һәм аннан соң да тынлы оркестр фронт еллары һәм сугыш маршлары көйләрен уйнады, шуңа да бәйрәмгә килгән ветераннар вальс әйләнгәндә яшьлекләрен, фронтташ дусларын һәм башкаларны искә төшергәннәрдер, мөгаен. Әмма бәйрәмдә Бөек Ватан сугышы ветераннары гына түгел, әфганчылар да, Чечня сугышы ветераннары да, киләчәктә хәрби хезмәткә чакырылачак егетләр дә - бер сүз белән әйткәндә, Ватан сагында торган һәм киләчәктә торачак кешеләр җыелган иде. Октябрь районы хәрби комиссариаты исеменнән М.С.Абдрахманов чыгыш ясап, бирегә җыелучыларны бәйрәм белән котлады. Бөек Ватан сугышында катнашучылар исеменнән легендар танкист Василий Иванович Спасов чыгыш ясады. Чал чәчле ветераннар «Ветеран» клубы берләшмәсен оештырып кына калмыйча, үз вокаль ансамбльләрен дә булдырганнар. Аның кичәдә чыгыш ясавы һәркемгә дә ошады. «Баллада» хореографик композициясе Әфганстанда һәлак булган биш якташыбыз истәлегенә багышланган иде. Аны мәдәният йорты каршындагы «Норлат» бию коллективы башкарды. Чечня җирендә улы каты яраланган Лидия Ивановна Арбузова чыгышы да кичәдә катнашучылар өчен дулкынландыргыч булды. Ә Лидия Ивановна һәм башка солдат аналарына багышланган җырны Светлана Ефремова башкарды.

Бәйрәм азагында аны алып баручылар бездә сугышчы исеменең һәрчак почетлы булуын һәм һичкайчан куркыныч булмавын теләделәр.

П.ДОЛГАНОВ.

## М.Бакиров призына

Әфганстандагы сугыш ветераннары һәм инвалидлары берлегенең җирле бүлекчәсе, химаячеләрнең турыдан - туры ярдәме белән, Әфганстанда һәлак булган Миншакир Бакиров призына менә инде икенче ел милли көрәш буенча ярышлар үткәрә. 22 февральдә бу ярышлар Түбән Норлатта үтте. Аларда йөздән артык спортчы - Октябрь, Аксубай, Чистай районнары вәкилләре катнаштылар. Көрәшчеләр унбер үлчәү категориясендә көч сынаштылар. 60 килограммга кадәр үлчәүдә Түбән Норлаттан Нияз Вәлиев җиңүче булды. 65 килограммга кадәр Раил Әхмәтҗанов (Чистай), 65 килограммнан авыррагында Ильяс Садыйков (Чулпан) һәм башкалар беренче булдылар. Ит комбинаты, элеватор, ГАИ, НГДУ сөт - май комбинаты, НУАД, «Кондырча» КХАсы ярыш химаячеләре булдылар.

П.ДОЛГАНОВ.

## ГАЛИМНӘР КИЛГӘН ИДЕ

Район хакимияте, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе агропромышленность комплексында хуҗалык итүгә реформалар уздыру, игенчелектә һәм терлекчелектә яңа технологияләрне кулланылышка кертүне тәэмин итү максатларында узган атнада хуҗалык җитәкчеләре һәм белгечләренең ике көнлек уку - семинарын оештырдылар. Тыңлаучылар алдында республика Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министрлыгы, Татарстан «Агробизнес» институты, фәнни - җитештерү берләшмәләренең абруйлы белгечләре чыгыш ясады.

Беренче көнне хуҗалык җитәкчеләре дә, белгечләр дә катнашкан пленар занятиедә «Агробизнес» институты доценты С.М.Котенков авыл хуҗалыгында реформалау уздыруга бәйле мәсьәләләр турында сөйләсә, «Кукуруз» фәнни - җитештерү станциясе башлыгы Б.С.Садыйков кукурузны бөртек өчен һәм бөртек технологиясе буенча игү, «Татарстан кыры» фәнни - җитештерү берләшмәсенең «Ашамлык бодае» төркеме җитәкчесе И.Ф.Левин югары җилемсәле кыйммәтле бодай игүнең алшартлары һәм бу эшнең технологиясе турында сөйләделәр. «Агробизнес» институты доценты Г.А.Юсинның чыгышы малларны ясалма орлыкландыру эшен тиешенчә оештыруга бәйле мәсьәләләр турында иде.

Икенче көнне белгечләр секцияләргә бүленеп шөгыльләнделәр. Башагрономнар һәм баш инженерлар алдында «Татарстан кыры» фәнни - җитештерү берләшмәсенең кафедра мөдире Н.К.Мәҗитов туфрак эшкәртүдә кулланылачак яңа техника, шул ук берләшмә фәнни хезмәткәре Х.З.Кәримов игенчелек культураларының Татарстанда чыгарылган яңа сортлары белән таныштырдылар.

Баш зоотехниклар һәм ветеринария табиблары башта көтүне янартуның мөһим алшарты буларак терлекләрне ясалма орлыкландыру мәсьәләләре белән җентекләп танышсалар, республика Авыл хуҗалыгы министрлыгының терлекчелек бүлеге начальнигы урынбасары Ф.Х.Газизов терлекчелектә малларны карау һәм ашатуның яңа технологияләренә тукталды.

Баш бухгалтерлар һәм икътисадчылар секциясендә сүз авыл хуҗалыгында реформалар уздыруга бәйле мәсьәләләр хакында барды.

## ХУҖАЛЫКЛАРДА ЕЛЛЫК ХИСАП

**Районның крестьян хуҗалыклары ассоциацияләрендә еллык хисап җыелышлары башланды. Аларның беренчесе «Родина» хуҗалыгында узды**

## КУШКАНГА ГЫНА ЭШЛӘП ЯХШЫ ЯШӘП БУЛМЫЙ

Салдакай - районда чуваш һәм татар халкы тел аермасын да, башкасын да сизмичә, хәтта ул турыда уйларына да китереп карамыйча үзара дус булып, туганлашып яши торган уникаль авыл. Шуңа күрә хуҗалык рәисе Н.Е.Евлампьевның рус телендә ясаган хисап докладыннан соң фикер алышуларның үзеннән - үзе бер - чуваш телендә генә китүенә гаҗәпләнәсе юк иде. Хәер, мондый бердәмлеккә, татулыкка гаҗәпләнергә түгел, ә киресенчә, сөенергә кирәктер әле. Ник дисәң, родиналыларның соңгы елларда игенчелектә һәм терлекчелектә районда әйдәп баручылар рәтенә чыгуы, күп кенә социаль - көнкүреш проблемаларын кешедән алда хәл итүе бер яктан шулар белән дә аңлатыла торгандыр. Эшкә булган халык бу авылда, шуңа күрә чөгендер ташырга машина сораудан кала читтән кеше чакырганнары юк. Һәм шул үз көчләре белән ашлыгын - чөгендерен, сөтен - итен, хәтта йонын да күп кенә хуҗалыклардагыдан артыграк җитештерәләр һәм саталар. Яшерен - батырын түгел - «Родина» районда дуңгызчылыкны саклап калышкан санаулы хуҗалыкларның берсе. Хакыйкать хакына әйтергә кирәк, җыелыштагылар уңышларының элеккеге рәис Рәфис Рәфыйк улы Хәмзин исеме беләндә шактый нык бәйле икәнлеген әйтеп үтәргә онытмадылар.

Эшләре шулай уң булгач, бу хуҗалыкның алга таба да тотрыклы атласына шик булырга мөмкин түгел төсле. Быелга җитештерү - финанс планы проекты да «максат ирешелгәннәрне саклап, хәлдән килсә биеккәрәк үрмәләүдән гыйбарәт» дигән принциптан чыгып төзелгән иде. Ул шулай кабул ителде дә. Чөнки, иген уңышын күтәрү өчен минераль ашламаны шактый гына туплап куйдык, терлек азыгы малларны исән - сау кышлатырга җитәрлек, техниканы язга хәзерләү әйбәт кенә бара дип тынычландыргач, нәрсә дип борчылырга ди соң әле?!

Әмма, уйлана калсаң, шулай тынычланырга урын бармы икән соң? Юк төсле. Идарә рәисенең хисап докладында китерелгән кайбер саннар ук нык уйландырырга тиеш иде. Бигрәк тә продукциянең үзкыйммәте турындагылары. Соңгысы әлегә аны дәүләткә сату бәясеннән шактый югары һәм шуңа күрә дә еллык нәтиҗәләр буенча рентабельлелек дәрәҗәсе «нольгә» тигез булу, продукция сатудан кергән акчаның (әле анысы да гел акчалата түгел бит) нигездә хезмәт хакы түләүгә китеп баруы гаҗәп түгел. Николай Евгеньевичның бу хуҗалыкка рәислек итә башлавына күп түгел әле, шуңа күрә аның еллык эшкә анализ ясаганда бик тирәнгә кермәвен аңлап та була. Ә гомер буе шушы авылда яшәп эшләүче төп белгечләр? Кызганычка каршы, аларның чыгышларында ни үзкыйммәт, ни урынсыз һәм акланмый торган чыгымнар мәсьәләсендә бер генә җитди фикер дә, тәнкыйть сүзе дә ишетелмәде. Һич югы үзләре җитәкли торган тармакларда нинди файдаланылмаган резервлар барлыгы турында әйтеп үтәргә тиешле белгечләрнең сүзе «бездә нигездә халык әйбәт, тырыш, кушканны эшлиләр, әмма кызганычка каршы, кайберәүләрне үгетләргә туры килә шул әле...» диюдән әллә ни ерак китмәде. Әле ярый баш инженер, исемнәрен әйтмичә булса да, бер кешене кырыкка ярырдай вакытта өйдә бот күтәреп ятучылар күп икәнлеген искәртеп узарга җөрьәт итте. Югыйсә, читтән килгән кеше, продукция җитештерү буенча районда алдынгылар рәтендә баручы салдакайлыларның бар кыенлыклары да бүген бөтен ил башына төшкән икътисадый һәм финанс афәтләреннән генә икән дип уйлап китәр иде.

Ә кушканга эшли торган заманмы соң бүген? Продукциясе ярыйсы ук мул булгач, аның ни бәрабәренә җитештерелүе, күпмегә төшүе, ул чыгымнарны ничек итеп киметү турында уйлап баш ватмый торган заманмы? Әнә шулай кушканга гына эшләп йөрүчеләр күп булганга күрә механизаторларның кызу эш өстендә нормадагыдан артыграк эшләгән сәгатьләрен исәпкә алу һәм аларга ничек түләү турындагы сораулар еллык җыелышта кузгатыла да торгандыр инде ул. Шуңа күрә дә бүген авылда көн кадагына куелган мәсьәлә - эш кешесен чын хуҗа да иттерү юллары турында бу җыелышта җитди сүз кузгатылырга тиеш булгандыр. Дөрес, идарәдә аренда звенолары оештыруның проекты бар инде, әмма яз ишек төбендә торганда ул эшне ашыктырмыйча ярамый. Тик ашыгычлык белән мәсьәләнең асылы күз уңыннан җибәрелә күрмәсен - ул эш тә кушканга гына эшләнмәсен иде. Җыелышта катнашып чыгыш ясаган хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев та, родиналыларның хезмәтенә тиешле бәя биреп, аларның алга таба продукция муллыгы хакына гына түгел, ә хезмәтләре үзләренә дә куаныч һәм канәгатьлек китерерлек итеп эшләүләрен теләде, моның өчен һәр тармакта эшкә җитди икътисадый анализ ясап, чыгымнарны мөмкин кадәр киметү юлларын эзләргә, шул җөмләдән җиргә һәм башка матди байлыкларга чын хуҗалар табуга юнәлдерелгән реформалар уздыруга кыю төстә алынырга чакырды.

Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.

**Акцияләр сатып алабыз**

«Татнефть» АҖнең Б категорияле,
«Сургутнефттегаз» АҖ,
«ЛУКойл НК» АҖ,
«ЛУКойцл - Лангепаснефтегаз» АҖ,
«ЛУКойл - Урайнефтегаз» АҖ,
«ЛУКойл - Когалымнефтегаз» АҖ,
«Ноябрьскнефтегаз» АҖ,
«Газпром» РАҖ акцияләрен.

Безнең адрес: «Сервистехинвест» ЧИФ. К.Маркс ур., 12 (ишеге яннан).
Тел.: 2 - 19 -30.

## ЭШКӘ БИРСӘҢ ЧЫН КҮҢЕЛ

# СЫНАЛУ

Авыл яшьләре гадәттә авыл хуҗалыгы белгечләре әзерли торган уку йортларына керергә тырыша. Николай Белов та шулай итте: документларын Ульяновск авыл хуҗалыгы институтының ветеринария факультетына илтеп тапшырды. Аннан... лекцияләр, лаборатор занятиеләр һәм практика аңа хайваннар турында бик күп яңалыклар ачты. Иң әһәмиятлесе, ул үз һөнәренең төп таләпләренә - малларга карата бик игътибарлы булырга, аларның тазалыгы турында даими кайгыртырга кирәклегенә төшенде.

Институттан соң Николай шунда, Ульян өлкәсендә үк эшкә калды. Аннан инде ветеринария табибы белгеченә шулай ук мохтаҗ булган туган авылына кайтты. Ул чакта аның бу карарга килүенә озак еллар зур җаваплы эшләрдә, урыннарда эшләгән әтисе Леонид Федоровичның тәэсире зур булды. Улының авылга кайтып крестьян хезмәтенә алынуына «Россия» колхозының даны районга билгеле терлекчесе, дуңгыз караудагы казанышлары өчен зур мәртәбәләргә ирешкән, заманында Ленин ордены белән бүләкләнгән әнисе Зинаида Якимовна да бик куанды.

Яшь белгечне хуҗалыкның баш ветеринария табибы итеп, җаваплы да, катлаулы һәм мәшәкатьле дә эшкә билгеләделәр. Беренче елы бик авыр булды, әмма Николай Леонидович үҗәтлеге белән алдырды. Яшьтән үк канына сеңгән кагыйдә - яраткан эшеңне ахырына җиткерергә кирәклеге дә булышты аңа. Барысына да өлгерергә омтылып, малларга прививкаларны да вакытында ясарга тырыша, ясалма орлыкландыру эшен дә дәвам иттерә, терлекчеләр белән дә яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыра. Мөһим мәсьәләләрдә мөстәкыйль рәвештә карарлар кабул итәргә дә кыюлыгы җитә абруйлы белгечнең һәм алары дөрескә чыгып, уңыш та китерә. Беловның эшен районда башкаларга үрнәк итеп куя башлыйлар. Ә ул һаваланмый - нитми, киресенчә, башкалар тәҗрибәсен дә, фән яңалыкларын да өйрәнүен дәвам итә. Үзе дә җиң сызганып эшли, башкаларга да таләпчән.

«Безнең эшнең бер үзенчәлеге бар - ветеринар һәр эшне үзе башкара. Ә Белов иренә торганнардан түгел, шуңа күрә хезмәтенең нәтиҗәсе дә күркәм», - диде аның турында районның баш ветеринария табибы Г.Ш.Кыямов.



Соңгы елларда терлекчелек алдынгылары слетларында Белов фамилиясе яхшылар рәтендә телгә алына. Хаклы рәвештә, эшенең нәтиҗәләренә карап. Менә быелгы слетта да шулай булды. Фотохәбәрчебез дә аны шунда рәсемгә төшереп алган иде.

Хәзер Николай Белов алдында тагын бер зур сынау тора. Ул ике хуҗалыкны берләштергән Кузнецов исемендәге КХАга баш ветеринария табибы итеп куелды. Грамоталы белгечкә бу юлы да өмет багълыйлар. Николай Леонидович монда да сынатмас дип ышанасы килә. Сыналган белгеч бит ул.

**Т.НАЗАРОВА.**

**Рәсемдә: Кузнецов исемендәге КХАның баш ветеринария табибы Н.Л.Белов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Тирәбездә яхшы кешеләр

# ЙӨРӘК ҖЫЛЫСЫН КУШЫП

Укытучы балаларны яратырга тиеш, диләр. Әмма һәрвакытта да ул балаларның мәхәббәтен яулый аламы - бусы шулай ук мөһим сыйфат бит. Ә менә Андреевка урта мәктәбенең икенче класс укучылары бертавыштан кабатлыйлар: әйе, без Вера Аркадьевнаны бик яратабыз. Аларга ата - аналар да кушылалар: без дә Вера Аркадьевнаны бик хөрмәт итәбез. Шундый югары бәягә, уртак мәхәббәткә ничек ирешкән соң авыл укытучысы?

Безгә калса, хезмәте белән педагоглык эшендә ул бал корты төсле тырыш, бар энергиясен, җан җылысын, мәхәббәтен укучыларына биреп хезмәт куючы укытучы. В.А.Абрамованың дәресләре танып белү ягыннан гына түгел, тәрбияви юнәлештә дә гаҗәеп эчтәлекле, аларда гаделлек, шәфкатьлелек тулып тора. Укытучы һәр укучысы күңеленә юл тапкан, ул - аларның сердәше дә, киңәштәше дә, өлкән дусты да. Бу мөнәсәбәт дәресләрдә дә, аннан тыш вакытларда да саклана. Дәресләрендә ул укучыларын ничек тә битараф калдырмаска тырыша: гаҗәпләндерә дә, сокландыра да, уйландыра, шатландыра да. Ә яхшыны яманнан аерырга өйрәнеп үскән балалар тормышта да битараф булмаячаклар бит. Вера Аркадьевна моны күпьеллык хезмәт нәтиҗәсендә белә. Әнә алдагы елларда аңардан белем алган яшьләр әле дә мәктәп, укытучылары тормышы белән кызыксынып торалар, хәлләреннән килгән ярдәмне дә тәкъдим итәләр.

Күптән түгел мәктәптә дәресләрдә үзара катнашу үтте. Без, коллегалары Вера Аркадьевнаның никадәр ныклы белем бирүенә, эзләнеп эшләвенә тагы бер кат инандык. Ул үткәргән класстан тыш чаралар, экиятләр буенча КВН зур бәйрәм рәвешен алды, ул укучылар күңелендә озак сакланыр дип уйлыйбыз. Һәм, гомумән, тормыш юлында аны очраткан нәниләр бик тә бәхетлеләр: алар чын шәфкатьлелек, игелек, гаделлек белән аралашалар бит! Ә Вера Аркадьевнаның игелекле тыйнаклыгы - үзе зур хәзинә: әнә ул бер укучысын өенә барып укытырга да вакыт таба, калганнарына да күңел җылысын кызганмыйча өләшә.

Коллегабызның бу көннәрдә юбилее була. Без аңа күпсанлы укучылары, укытучылар коллективы, ата - аналар исеменнән озын сәламәт гомер, бәхет телибез. Балалар мәхәббәтен, олылар хөрмәтен яулаган укытучы В.А.Абрамова моңа бик лаек дип уйлыйбыз.

**Укытучылар һәм ата - аналар исеменнән - В.ИВАНОВА, Ф.ГРАЧЕВА һәм башкалар.**

## *Галимнәр киңәш бирә*

# СОЯ ИККӘН ҮКЕНМӘС

***Мөстәкыйльлеккә таба йөз тотучы Татарстан Республикасы үз халкын азык-төлек белән тәэмин итүне күбрәк үз көче белән хәл итәргә омтыла. Бездә моңа мөмкинлекләр бар. Чәчүлекләр мәйданы бәрәмлегенә һәм җан башына авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү буенча Татарстанның Россиядән шактый алда баруы бәхәссез. Әмма республикабыз халкын туклану продуктлары белән өзлексез тәэмин итүдә проблемалар да шактый.***

Беренчедән, Татарстан үзен иң кирәкле продуктларның берсе-үсемлек мае белән җитәрлек күләмдә тәэмин итә алмый.

Икенчедән, соңгы елларда терлекчелектә шактый сизелерлек уңышларга ирешелсә дә, 100 гектарга исәпләп караганда ит һәм сөт җитештерү күләме Татарстанда әле һаман түбән дәрәҗәдә кала бирә. Моның төп сәбәбе - рационнарның протеин буенча балансланмаган булуында. Аның тискәре нәтиҗәсе бик тиз сизелә: хайваннарның продуктлылыгы кими, азык кирәгеннән артык сарыф ителә, терлекчелек продукциясенең үзкыйммәте күтәрелә. Протеин җитмәүче азыкның үзләштерелү дәрәҗәсе 25 процентка кадәр түбәнәергә мөмкин. Шуңа күрә терлекчелекне яхшы сыйфатлы, аксымга бай азык белән тәэмин итү - республика алдында мөһим мәсьәлә. Бу үзара тыгыз бәйләнгән ике проблеманы - үсемлек маен кирәк кадәр җитештерү һәм терлекләр өчен протеин буенча балансланган азык булдыру мәсьәләсен ничек, нинди юллар белән хәл итәргә мөмкин соң?

Америка Кушма Штатлары үз халкын үсемлек мае белән тулысынча тәэмин итеп тора. Бу казанышның сере - турыдан - туры соя игү белән бәйле, төгәлрәге, аны төрле яклап файдалану мөмкинлеге. Соя орлыгының маен сыгып чыгаргач кала торган майсыз түп (шрот) һәм түп (сыгынты) кош ите җитештерүдә төп азык булып тора.

Сояда аксым күләме 55 процентка кадәр җитә. 100 грамм борчакта - 336, бодайда - 347, ә сояда 411 калория бар. Туклыклы кыйммәтлелеге ягыннан соя аксымы үсемлек аксымнарының иң яхшыларыннан санала, ә аминокислоталар составы буенча ул иттәге аксымга якынлаша.

Соянын биологик сыйфатлары искиткеч шәп. Гектардан 25 центнер уңыш алу 10 процентка якын чи протеин алу дигән сүз, ә бу инде, үз чиратында, 110 центнер арпага тәңгәл. Чәчүлек мәйданы бәрәмлегеннән аксым чыгу буенча соя башка күп культураларны узып китә. Анардан алына торган протеин иң арзанлылардан. Керем ягыннан да иң табышлы культуралардан санала. Соя аксымы нигездә суда эрүчән протеиннардан тора һәм югары сыйфатлылыгы белән күзгә ташлана. Аксымнарның үзләштерелү дәрәҗәсе дә югары. Туклыклылыгы ягыннан соя мае иң яхшы үсемлек майларыннан санала, бу сыйфаты белән ул хәтта ак майны да уздыра. Соядагы төп протеин - глицинин, әчи башлагач эреп төшә, ә бу инде соядан ашамлык продуктларын алуны күбәйтергә, аларны төрлеләндерергә мөмкинлек бирә.

Соянын майсыз түбе (шроты) бик арзан продукт. Аның 1 килосында 354 грамм үзләштерелүчән аксым, 1 кило бодай онында 2,5 грамм, ә шул ук күләмдәге соя онында 27 грамм лизин (аминокислота төре), 1 кило соя орлыгында 1,37 - 1,47 азык берәмлеге һәм 275-338 грамм үзләштерелүчән протеин бар.

Татарстан кырларының 36 процентын терлек азыгы культуралары били. Бөртекле ашлык уңышының да шактый өлеше бүтән максатларда файдаланыла (мәсәлән, фураж итеп). Ягъни басуларның күп өлеше гел терлекчелеккә хезмәт итә булып чыга.

Исәп - хисаплар шуны күрсәтә, чәчү әйләнешенә соянь керткән очракта (терлек азыгының аксымлы өлеше арту бәрабәренә) фураж культуралары мәйданын киметергә, ә югары сыйфатлы каты һәм көчле бодай басуларын киңәйтергә мөмкинлек туачак.

Биләгән мәйданы, кузаклы һәм майлы культураларның уңышы буенча соя дөньяда беренчелекне тота (43 процент).

Соя җылы һәм дымлы җәйне ярата. Аның орлыклары 5-6 градус җылыда шыта башлый. Язын 2,5 градус кырауларны ансат кичерә. Ул комлы кара туфракта яхшы уңа, хәер, башка төр туфракларда да әйбәт уңыш бирә, ләкин авыр, әче туфракны, сазлыклы урыннарны яратмый. Күрәсез, бу культураны игү өчен Татарстанда бөтен шартлар да бар.

Чәчү әйләнешендә соя гадәттә уҗым культураларыннан соң урнаштырыла. Азотка бай кузаклы үсемлек буларак, ул бездә дә сабан культуралары өчен менә дигән элгәр була ала.

Соя игүгә керешү Татарстан Республикасы халкын җитәрлек күләмдә үсемлек мае, ә терлекчелеген аксым ягыннан балансланган азык белән тәэмин итүгә (димәк, бу тармакның рентабельлеген күтәрүгә), бодайның кыйммәтле сортларын күбрәк җитештерүгә юл ачачак.

**Ә.ХАЛИДОВ,**
**биология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры.**

**Р.ТАЛИБУЛЛИН,**
**Алабуга педагогия институтының биология кафедрасы мөдире, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты.**

**(«Ватаным Татарстан»ның быелгы 15 февраль санынннан кыскартып алынды).**

# ШӘҺӘРЕБЕЗ: КЕШЕЛӘРЕ ҺӘМ ЭШЛӘРЕ

# СЕМБЕРДӘ НЕФТЬ ФОНТАНЫ

## Аны Норлат бораулаучылары ачты

Яңа елны җиңү рапортлары белән каршылый алмады быел Норлат разведка бораулавы идарәсе коллективы. Башкарылган эш күләмен процентларга күчереп исәпләгәндә «100»-ле саны бөтенләй телгә кермәде. Бораулау предприятиеләренең төп шөгыле тирән катламнары үтү санала бит. Менә шул, бу күрсәткеч буенча эш күләме 1995 елдагыдагының нибары 70 проценты чамасын тәшкил итә. Скважиналарны файдалануга тапшыру планы да 10 процентка тулмады.

- Киң колач белән, җәелеп торып эшләргә мөмкинлек булмау бәласы,- дип аңлата моны идарә начальнигы Анатолий Насолдин. Ул шактый искергән, таушалган хуҗалыкны былтыр гына кабул итте. Әйтерең бармы, юньле-башлы мирас түгел инде бу. Нефть табуда, чыгаруда бай тәҗрибә туплаган белгеч кайчандыр Норлатта да эшләп киткән. Шуңа күрә ул чор белән бүгенгене чагыштыруы әллә ни кыен түгел аңа:

- Элек нефть чыганакларын үзләштерергә өлгерә алмый аптырый идек. Заказ өстенә заказ явып кына торды ул чакта. Ә хәзер нефть һәм газ чыгару идарәләре безне эшкә «тилмертәләр». Чөнки финанслау хәлләреннән килми башлады. Ифрат зур чыгымнар таләп итә шул бораулау эшләре,- ди идарә башлыгы.

Эше булмагач, әҗере дә юк, дигәндәй, коллектив базар икътисадының төп шаукымы - эш урыннарын кыскартудан котыла алмаган. Байтак кына «алтын казык»тай кадрлар белән хушлашырга туры килгән. Норлаттагы 9 бригаданың 3 се таркалган килеш. Алабугада тагын 5 бригада бар икән әле. Шулар белән җәмгысе 1500 гә якын кеше эшли хәзер биредә. Теләсә нинди каты токымнарны җимерә торган, оста куллы, булдыклы халык кына калган. Ике кулга бер эш кенә булсын аларга.

Авыр заманнар кичерсәләр дә, нефтьчеләр арасында артык боегу, тәшвишкә бирелү сизелми барыбер. Идарә җитәкчесе үзе дә киләчәккә ышаныч белән карый, алдагы елда икътисадый хәлнең яхшырачагына өмет итә.

Эзләнгән таба, үз дигәненә ирешә ул. Былтыр җәй күршеләр - Ульяновск өлкәсендә «хәзинә»гә тап булдылар. Хәзинә дигәннән, андагы «Нафта - Ульяновск» фирмасы белән үзара отышлы килешү төзеделәр. Тегеләр гаять мул «кара алтын» ятмаларына юлыкканнар икән. Ә менә шуны бораулларга эшче көч, технология, техника юк. Үзләренә эшкә Норлат нефтьчеләрен чакырдылар. Хәзер Аллагөл нефть чыганагында идарәдән бер бригада каты токым тишү белән мәшгуль, икенчесе эшкә керешергә җыена. Менә сиңа тагын 200 кешегә акчалы эш урыны. 4 скважина куярга өлгергәннәр дә инде. Берсе файдалануга тапшырылган. Әйтүләренә караганда, «җир мае» бәреп чыгарлык. Шуннан соң Ульян ягында янә бер нефть чыганагын үзләштерү буенча үзара килешүгә имзаларын төшергәннәр.

Әлбәттә, болар гына эшсезлек проблемасын тулысынча каплый алмый, әмма акмаса да тамып торырлык булган. Шунысы да игътибарга лаек, маяга бераз керүгә, аны беренче чиратта нефтьчеләргә уңайлы хезмәт шартлары тудыруга, саулыкны ныгытуга юнәлдерәләр. Бер генә мисал. Көне-төне вахтада торучы таза бәдәнле ир-атлар янәшәдәге ашханә юлын онытты-лар. Бик барырлар иде, акча юк, туклану хакы да кыйбат. Ә каты-коты белән тамак ялгарга мәҗбүр булган кеше әллә ни майтара алмый. Идарә башлыгы ашаучү бәяләрен кимету, иң мөһиме-аласы хезмәт хакы исәбенә ашату җаен тапты. Туклану бәясе, кайсы айда ашалган, шул ай хезмәт хакыннан тотыла. Сүз җаеннан шуны да әйтик, нефтьчеләргә декабрь аеның хезмәт хакын гыйнварда өләштеләр. Кредитка алып. Идарәнең финанс торышы һич тә ал да гөл түгел. Районның күмәк хуҗалыкларыннан берничә миллиард сум аласы бар. Үзе дә җирле бюджетка 2 миллиард сум бурычлы. Әрсезләнеп анысыннан котылу юлын тапканнар. Норлатның суга интегүен күреп, район администрациясенә шул әҗәт исәбенә Мамык ягыннан су торбалары сузарга тәкъдим ясаганнар. Билгеле, монысы да зур чыгымнар сорый. Яңа скважина казырга, насос станциясе төзергә, 20-30 чакрымда су торбалары салып чыгарга кирәк. Аның каравы, күпме кеше эш белән мәшгуль, материалын «Татнефть» акционерлык җәмгыяте биреп баргач, аптырамыйлар. Бүген үк инде күзгә күренерлек эшләре бар.

Төзелеш белән нык-лап шөгыльләнергә мөмкинлекләре чикле менә. Алай да үз көчләре белән котельняны, балчык чыгару заводын тиздән файдалануга тапшырырга торалар. Санаторий - профилакторий бинасын яңадан үзгәртеп кордылар. Башлыча чит ил җиһазлары куелган якты, иркен сәламәтлек үзәге берьюлы никадәр кешене сихәтли ала. Сәламәтлек турында кайгырту кайгысы белән яшәгәч, «үлми» әле бораулаучылар коллективы.

**Илдус Диндаров,**
**үз хәбәрчебез.**
**(«В.Т», 19 февраль,1997 ел).**



# КЫЕНЛЫКЛАР... ФАЙДАГА?

НГДУның ,структур подразделениесе булган технологик транспорт идарәсе (УТТ) - районндагы иң эре транспорт предприятиеләренең берсе. Биредә нефть чыгаруга хезмәт итүче махсус техника гына да 440 берәмлек исәпләнә. Нефтьчеләр йөртү өчен вахта техникасы бар. Скважиналар ремонтлау, гомумән, нефть чыгаруга бәйле бер генә объектка да транспортчыларның өлеше кермичә калмый. Идарәнең базасы да нык. Районда нефть чыгаруга бәйле рәвештә оештырылган бу идарәдә 15 ел эчендә нормаль эш өчен бөтен шартлар булдырылды. Алты колоннаның һәрберсендә җылы гаражлар, ремонт базалары бар. Ярдәмче цехлар да җитәрлек. Столярлык, мотор, электр, аппаратура, аккумулятор, эретеп - ябыштыру, токарьлык цехлары заман таләпләре нигезендә корылган. Бер дигән техник хезмәт күрсәтү, ягулык салу станцияләре бар. Гомумән, хезмәт күрсәтү базасы теләсә нинди оешма көнләшерлек. Хәер, көнләшерлек дигәннән, УТТда эшләүдә райондагы теләсә кайсы транспорт предприятиесендә эшләүгә караганда да мәртәбәле, шул ук вакытта авыр, җаваплы. Бу очракта эшләгән кешенең, кем әйтмешли, акчасын көрәп алуы, шул ук вакытта эчәргә, тәртип бозарга «маһир» кешеләрнең биредә бер көн дә эшли алмаслык шартларга куелуы турында әйтүем. Автотранспортчылар, хәтта слесарьлар өчен көнгә ике тапкыр медицина тикшерүе узу, спиртлы эчемлекләр кулланып бер тапкыр тотылган кешенең эштән азат ителүе нормага әверелгән. Узган ел үлем очрагы белән тәмамланган юл - транспорт фаҗигаләренең бөтенләй булмавы да дисциплинаны ныгытуга юнәлдерелгән «кырыс» шартлар нәтиҗәсе, дип санылар җитәкчеләр. Ә бүгенге көндә эшсез калырга, алай гына да түгел, нормаль эшләгәндә яхшы хезмәт хакы гарантияләнгән әлеге оешма рельсыннан «төшеп» калырга теләмәгән һәркем биредә кем әйтмешли, ябырылып ятып эшли. Соңгы елларда кадрларның алышынуы да бөтенләй беткән диярлек.

Шулай да бүгенге икътисади тотрыксызлык кайчандыр стабиль эшләгән оешма эшчәнлегенә дә тискәре йогынты ясамыйча калмады. 1992 нче елда, мәсәлән, УТТда техниканы линиягә чыгару коэфициенты 0,6 тәшкил итә иде. Аннан соңгы елларда, ягъни НГДУның нефть чыгару буенча иң нәтиҗәле эшләгән чорында да идарәнең структур подразделениесе булган УТТда хезмәтнең нәтиҗәлелеге кимемәде.

Дөрес, идарәнең былтыргы күрсәткечләре дә яманларлык түгел. Пландагы 150 мең тонна урынына 156,1 мең тонна йөк күчерелгән. Бер кешегә эшләп чыгару күрсәткече дә планлаштырылганнан югары. Техниканы линиягә чыгару коэфициенты да 0,555 булган. Шулай да идарә начальнигы И.Г.Вәлиуллин канәгать түгел:

- Тулы торгынлыкта без,- ди ул һәм санап китә: финанс кытлыгы, эш фронты азаю һәм башкалар...

Алайга китсә, финанс кыенлыгы кайсы оешманы читләтеп үтә икән хәзер? Шул сәбәпле узган елдан идарәнең үз исәп - хисап счеты ябылган һәм ул НГДУ составындагы бер цех булып кына калган. Димәк, финанс бәйлелеге дә барлыкка килгән. Ә бу матди ихтыяҗларны канәгатьләндерүне чикли. Әйтик, элегрәк идарә ел саен 60 - 70 берәмлек техника юнәтә торган булган. Ә менә соңгы ике елда техника паркы бер генә техникага да артмаган. Өстәвенә запас частьләр юнәтү эше дә мәшәкатьле: еш кына искеләрен яңартып канәгатьләнергә туры килә.

Гомумән, заман акчаны һәр адымда санарга мәҗбүр итә. Штат минимумга кадәр кыскартылган. Нормадан тыш эшләү сәгатьләренә аерым учет алып барыла. Техникага сак карaш булдыру, запас частьләр, ягулыкны сарыф итүгә контроль көчәйгән.

- Бу - заман таләбе. Юрганга карап аяк сузарга туры килә,- ди Исхак Гарифуллович һәм өсти: нефть ятмаларында запас булганда һәм НГДУ тулы көченә җир мае чыгарганда, безнең өчен дә эш фронты бетмәячәк. Ә бүгенге кыенлыклар исә коллективның эшкә сәләтен арттыра да төшә әле.

Шулай гына була күрсен.

**Р.ГИНЯЕВА.**



Пар һәм су белән тәэмин итү цехы (ЦПВС) - «Норлатнефть» НГДУсының эре һәм мөһим ярдәмче цехларының берсе. Бу цехның житештерүчән эшләве байтак башка цехлар эшчәнлегенә дә тыгыз бәйләнгән. Цех үзе исә берничә бригадага бүленгән. Виктор Долгов эшли торган БПО территориясендәге 61 нче бригада коллективы да шулар составында. Виктор Михайлович үзе дүртенче разрядка ия оператор. Үз хезмәтенә һәрчак җаваплы карашта. Цех җитәкчелеге дә аның эшеннән һәрчак канәгать.

**Рәсемдә: оператор В.Долгов.**
**Н.Квашнина фотосы.**

# КУЛЬТИВАТОРЛАР ДА, ШКАФЛАР ДА

«Норлат машина төзү заводы» акционерлык җәмгыятендә заказларның һичкайчан бетеп торганы юк. Төрле модификациядәге көнкүреш суларын чистарту җиһазлары, культиваторлар һәм башкалар. КУТМ - 12 җиһазын сорап Уфа шәһәренең коммуналь предприятиесеннән кадәр үк килделәр хәтта. Культиваторларга да сорау зур.

Завод җитештергән халык куллануы товарлары да складларда ятмый. Менә инде бер еллап промышленность предприятиеләре өчен эш киемнәре шкафлары ясау белән шөгыльләнәләр. Технологик транспорт идарәсе, мәсәлән, биредә җитештерелгән шкафларны ошатып, заказ буенча үзләренә дә ясатып алды. Җылылык челтәре, электр станциясе дә шкафларга заказ бирделәр.

Болардан тыш, заводта сейфлар да ясала. Аның теләсә нинди үлчәмдәгесен, формадагысын ясау хәлләреннән килә. Валерий Феоктистов, Мәүлет Абдрахимовның слесарьлар, Хәниф Әхмәтвәлиев җитәкчелегендәге эретеп ябыштыручылар бригадалары бу эшләрне аеруча зур осталык белән башкаралар.

*Кем булырга?*



# Чит телне белү бик кирәк

Без - Биккол авылы кызлары. Хәзерге вакытта Алабуга дәүләт педагогия институтының татар теле, әдәбияты һәм чит телләр бүлегендә укыйбыз. Әлеге бүлекнең ачылуына 5 ел гына әле. Редакциягә хат юллавыбызның максаты бар: бәлки безнең киңәшебез кемгә дә булса файдага булыр.

Укытучылар җитешмәү сәбәпле авыл мәктәпләрендә чит тел укыту системалы алып барылмый, ә кайберләрендә бөтенләй укытылмый да. Мәктәптә чит телне ныклап өйрәнә алмаган укучының, әлбәттә инде, чит телләр факультетына укырга керергә мөмкинлеге булмый. Шунлыктан, укучыда чит телне өйрәнүгә омтылыш никадәр көчле булмасын, ул башка факультетларга кереп укырга мәҗбүр була. Ә без укый торган бүлек нәкъ шул проблеманы истә тотып төзелгән дә инде. Чит телләрне монда яңабаштан өйрәтә башлыйлар һәм бу бүлеккә укырга керү өчен дә татар теле һәм әдәбияты программасын белү җитә.

Әйткәнебезчә, бүлек әле 5 ел гына эшләп килә. Биредә чит телләрне (инглиз һәм немец телләрен) тәҗрибәле мөгаллимнәр алып бара. Алар студентлар белән саф татар телендә аралашалар һәм тирән белемнәр бирү өчен күп көч куялар.

Заманалар елдан - ел үзгәрә һәм чит телләрне белү кеше өчен ихтыяҗга әверелә бара. Шуңа да әле бүген мәктәптә укып йөрүче һәм киләчәктә кем булырга, кайда укырга дип баш ватучыларга киңәшләребез дә бар: безнең уку йортына килсәгез, үкенмәссез. Без үзебез дә 5 ел элек бу белгечлекне сайлавыбызга сөенеп бетә алмыйбыз.

**Л.НУРИҖАНОВА, Г.ШӘРӘПОВА.**
**Алабуга шәһәре.**

## Фикер катгый

Татарстан прокуроры С.Нәфиев рәислегендә республика хокук саклау органнары - Прокуратура, Эчке эшләр министрлыгы, Дәүләт иминлеге комитеты, Салым дәүләт инспекциясе, Салым полициясе федераль хезмәте, Татарстан Республикасының Хезмәт дәүләт инспекциясе, Милли банк, финанс министрлыгының контроль - ревизия идарәсе җитәкчеләренең координацион киңәшмәсе булды. Анда гражданнарның эшләнгән эш өчен түләү алу хокукын, шулай ук өлкән яшьтәге кешеләргә, инвалидларга һәм балигъ булмаганнарга пенсияләрне, пособиеләрне түләүне тормышка ашыру законнарының үтәлешен тикшерү мәсьәләсе каралды.

Бу максатта контроль ясаучы органнар җитәкчеләренең уртак боерыгы белән, хезмәткә түләүдәге бозуларны тикшерү өчен, үзәк аппарат хезмәткәрләреннән җиде эш төркеме төзелде. Алар кимчелекләрне бетерү буенча каттый чаралар күрәчәкләр, вазифадагы гаепле кешеләрне хәтта эштән алынуга кадәр дисциплинар һәм административ җаваплылыкка, административ бозулар турында Россия Федерациясе кодексында күздә тотылган штраф санкцияләренә тартачаклар.

Барлык бу катгый чаралар хезмәт иясе гражданнарның, пенсионерлар, инвалидлар һәм балаларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән.

Тикшерү уздырыласы конкрет шәһәрләр, районнар һәм предприятиеләр билгеләнде. Бер үк вакытта республиканың барлык шәһәр һәм районнарында җирле хокук саклау органнары һәм контроль ясаучы органнар урыннарда бердәм план буенча шундый ук тикшерүләрне башкарачаклар.

Март ахырында тикшерү йомгакларын карау, законнарны бозуга юл куйган предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләрен тыңлау күздә тотыла.

**Татарстан Республикасы Прокуратурасы матбугат үзәге, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының мәгълүмат һәм иҗтимагый элемтәләр бүлеге.**

*Үләннәрнең шифасы*

## БӨЕРДӘ ТАШ БУЛГАНДА

Үлән чәйләре:
1.Бәбкә үләне (үлән) 20,0
Канлы үлән (үлән) 10,0
Ак мәтрүшкә (чәчәк) 20,0
Нарат җиләге (яфрак) 5,0
Карлыган (яфрак) 10,0

1 стакан кайнап торган су салып, 2 сәгать төнәткәннән соң, көнгә 3 тапкыр ач карынга 1 әр аш кашыгы эчәргә.

2. Сидек реакциясе әче булган, фосфат тозы булган очракта:
Еланбаш (тамыр) 20,0
Әрекмән (тамыр) 20,0
Каешкыран (тамыр) 20,0
Кукуруз (сүсән) 15,0
Каен (яфрак) 15,0
Артыш (җимеш) 15,0

1 стакан кайнап торган су салып, су эчендәге савытта 5 минут кайнатырга 2 сәгать төнәтеп сөзгәч, 250 граммга җиткереп, ашар алдыннан 30 минут элек көненә 3 тапкыр 1/4 - 1/3 стакан эчәргә.

3. Сидек реакциясе селтеле булган очракта:
Наратбаш үләне (үлән) 30,0
Өч төсле миләүшә (үлән) 15,0

1 стакан кайнар суда 1-2 сәгать төнәтеп сөзгәч, ашар алдыннан 30-40 минут элек көнгә 3 тапкыр 1/3 стакан эчәргә.

4. Кәбестәнәң тамырын яндырып, ашаганнан соң көлен суга болгатып эчәргә.

5. 3 кг кара торманы уып, 4 сәгать торганнан соң, чиста тыгыз киндер салфетка аша сөзеп, бер стакан бал кушып болгатырга, 2 көн тоткач, ашар алдыннан 30-40 минут элек көнгә 3 тапкыр ай буена 1 әр аш кашыгы эчәргә.

6. 50г гөлҗимеш тамырын һәм 30 г ташъяргыч үләнен 2 стакан кайнар суда 2 сәгать төнәтеп, ашаганнан соң көнгә 3-4 тапкыр бал белән 1 әр стакан эчәргә.

7. 1 аш кашыгы төкле эт тигәнәген 1 стакан суда 2-3 минут кайнатып, 2 сәгать төнәткәч, ашаганнан соң көнгә 2 тапкыр 1/2 стакан эчәргә. Ташларны чыгарыр.

8. Чикләнмәгән күләмдә яшел петрушка ашарга ярый.

9. 70-80г кара әремгә 1 л кайнар су агызып 1 сәг. төнәткәч, 4-5л су өстәп ванна ясарга һәм көн саен 40-50 мин. утырырга. Ваннада су билне күмәрлек булсын. Дәвалану курсы - 15 процедура.

10. 20г бака үләненә (яфрагы, орлыгы, кәүсәсе белән) 300 мл кайнар су салып 1-2 сәг. төнәткәч, ашар алдыннан 30 мин. элек көненә 3 тапкыр 1/4-1/3 стакан эчәргә. Ташларны эретеп чыгарыр, аналыктагы авыртуларны басар, сидекне, хәйзне куар.

11. Юып киптерелгән кыр кузгалагы тамырын төеп, 50 мл чиста шәраб кушарга. Һәр көнне кичен, ашаганнан соң 2 сәг. үткәч, 20 көн буенча эчәргә. Бөердәге ташларны чыгарыр. Аналыктан кан килүне туктатыр.

12. Сарут орлыгын киптереп һәм төеп, иртә һәм кичен су белән ач карынга 4-5 г эчәргә. Сидек юлларын чистартыр, ташларны эретеп чыгарыр.

13. Көн саен 2-3 г петрушка яисә сельдерей орлыгын ашасалар яисә шул үләннәрне салат итеп файдалансалар, бөердәге ташларны эретеп чыгарыр, бөерне, сидек куыгын чистартыр. Сидекне, хәйзне куар. Иң куәтлесе, ташны эретә торганы - тау петрушкасы булыр.

14. Гипсны гөлҗимеш мае белән бутап тәнгә яксалар, сидек куыгыннан ташларны чыгарыр, кан килүне туктатыр.

15. 15 г чабыр үләненә 200 мл кайнар су агызып 2 сәг. төнәткәч, ашагач 1-2 сәгатьтән соң көненә 2-3 тапкыр 1/3 стакан эчәргә. Ташларны чыгарыр. Әмма йөкле хатыннарга ярамас, көмәнен куар.

16. 4,5 г артыш җиләген төнәтеп, ашаганнан соң 1-2 сәг. үткәч эчәргә. (Зыянын зирек төнәтмәсе алыр). Ташларны чыгарыр. Әмма йөкле хатыннарга ярамас.

17. Шифалы мәче борчагы орлыгын төеп, ашаганнан соң 1 сәг. узгач көненә 3 тапкыр 1 әр г эчәргә. Ташларны чыгарыр. Кан килүне туктатыр.

18. Сарут тамырын киптереп төеп, ашаганнан соң 1 сәг. узгач көненә 3 тапкыр су белән 1 әр чәй кашыгы эчәргә. Ташларны чыгарыр, сидек куыгын дәвалар.

19. Кычыткан орлыгын төеп, ашаганнан соң 1 сәг. узгач, көненә 3 тапкыр 1 әр г эчәргә. Бөердәге ташларны чыгарыр. Дәвалану срогы 12-15 көн.

20. Имәндә үскән аксыл мүкнең 30 граммын 10 процентлы 150 мл серкәдә 10 көн тотып сөзгәч, ашаганнан соң 1 сәгатьтән иртән һәм кичен 1 әр десерт кашыгы эчәргә. Үт куыгыннан һәм сидек юлыннан ташларны эретеп чыгарыр. Ваклап һәм иләп, иләк астыннан 0,5 граммын су белән эчсәләрдә тәэсире шундый ук булыр.

21. 40 г алма исле үләнне 400 мл кайнар суда 2 сәг. төнәткәч, 1 аш кашыгы бал салып болгатырга. Ашар алдыннан 1 сәг. элек көненә 3 тапкыр 1/4 стакан эчәргә. Шул рәвешчә 15-20 көн дәваланырга. Бөерне ачар, ташларны эретеп куар.

22. 20 г кыргый карлыганга 300 мл кайнар су салып, 2 сәг. төнәтергә. Ашар алдыннан көненә 3 тапкыр 1/4 - 1/3 стакан эчәргә. Бөерне сәламәтләндерер.

23. Кыр горчицасы орлыгын төеп, 3 граммын 30 мл шәраб белән ашар алдыннан 30-40 мин. элек көненә 2 тапкыр эчсәләр, сидек куыгындагы ташларны эретеп чыгарыр. Ашказанына файдасы булыр. 20-25 көн дәваланырга.

24. Гөлбадранның согын сыгып, ашаганнан соң 2 сәгатьтән көненә 1 тапкыр 1 әр десерт кашык эчсәләр, сидек юлындагы ташларны эретеп чыгарыр, сидекне куар. Эчтәге кортларны үтерер.

25. Торманы уып, согын сыккач, көненә 2 мәртәбә 15 г эчсәләр, сидек юлындагы ташларны куар. 10-12 көн эчәргә.

Шулай ук торманың эчен алып һәм 12 г шалкан орлыгы салып, өстен камыр белән сылап, кайнар күздә пешергәч, 3 көн дәверендә җылытып ашасалар, ташларны эретеп чыгарырга ярдәм итәр.

26. 8,5 г кыр әнечен зәйтүн агачы тамырының кайрысы белән бермә -бер микъдарда катнаштырып төяргә. Икегә бүлеп, ашаганнан соң 1 сәгатьтән көненә 2 тапкыр эчәргә. Шул рәвешчә 15-20 көн дәвам ителә.

27. 20 г ак мәтрүшкәгә 200 мл кайнар су агызып 2 сәг. төнәткәч, сөзеп, ашаганнан соң 30-40 минуттан 1/4 стакан эчәргә. Бөердәге ташларны куар. Йөкле хатыннарга ярамас.

28. Укроп сидекне һәм хәйзне куа. Ә кыргый укроп ташларны эретеп чыгара.

29. Инҗир җимеше һәм агачыннан чыккан сок бөердәге ташларны, комнарны куар.

30. 200 г кычыткан яфрагы, 15 г кылыч үлән тамыры, 10 г бөтнек, 15 г наратбаш үләне, 15 г артыш җимеше, 15 г гөлҗимешкә 300 мл кайнар су агызып, 3 сәг. термоста төнәткәннән соң, сөзеп, суын 300 мл га җиткерергә. Ашар алдыннан 40-50 мин. элек көненә 2-3 тапкыр җылы көенчә 1/3 стакан эчәргә. Бу кушылма бөердәге ташларны эретеп чыгарыр.

(«В.Т»).

## КОТЛЫЙБЫЗ!



Иске Әмзә авылында яшәүче әтиебез, абыебыз **Габдулла Имам улы Минаповка** февральдә 60 яшь тулды. Аны олы юбилее белән чын күңелдән тәбрик итәбез, саулык - сәламәтлек, бәхет - шатлыклар, кайгы - хәсрәтсез көннәр, озын гомер телибез.

**Кызы, кияве, оныгы, барлык туганнары.**



*Озак еллар иңгә - иң куеп бергә эшләгән кадерле хезмәттәшебез **Наилә Габдрахман кызы Хәмитованы** тормышындагы олы юбилее - 60 еллыгы белән чын йөрәктән котлыйбыз. Озын гомер, таза исәнлек, бәхет һәм шатлык телибез.*

*Гомер үтсен әйдә, чәч агарсын,*
*Ә йөрәккә кырау төшмәсен.*
*Килер көннәреңдә тик тазалык*
*Һәм шатлыклар гына өстәлсен.*

***Якын дуслары.***

## Белдерүләр

**Мамык инкубаторлык станциясе 1997 елның мартында чыгарылачак ит һәм ит - йомырка чебешләрен алуга чиратка яза.** Белешмәләр өчен тел.: 4 - 12 - 46, 4 - 12 - 47.

**Администрация**

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

***Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.***

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

***Бездә генә!***

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көнне, 28 февральдә көндезгә сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

**Аксеновның бизнес мәктәбендә**

**ике белгечлек буенча читтән торып укырга абитуриентлар кабул итү бара:**

**- бухгалтер - икътисадчы белгечлеге - уку срогы 1 ел.**

**- бизнес оештыру остасы - уку срогы 5 ел.**

**Уку түләүле, 1997 ел өчен 620 мең сум.**

Норлатта Совет ур., 119 - 2 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 2 - 15 - 61 (иртәнге 8дән кичке 4кә кадәр).

### *Сатабыз*

**2 һәм 3 камералы, зур сыешлы «Стинол» суыткычлары (Европача дизайн, арзан хак), шулай ук 2 һәм 3 камералы «Норд» суыткычлары. Район эчендә илтеп бирү - бушлай.** Тел.: 2 - 11 - 24.

***

**1994 елгы УАЗ - 3303 (йөк ташыгыч фургон).** Тел.: 2 - 21 - 02.

***

**1993 елгы ВАЗ - 21051, кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 28 - 24 (иртәнге 7 дән кичке 4кә кадәр).

***

**1994 елгы «Таврия».** Тел.: 2 - 22 - 67 (эш).

***

**Шәһәр эчендә коймаланган участок, 67000 км. йөргән «Москвич - 412».** Тел.: 5 - 17 - 66 (кичке 6дан соң).

***

**Чистарту корылмалары янында гараж.** Тел.: 5 - 17 - 76.

***

**Каралтылары белән йорт, мунчасы, коесы бар.** Адрес: Димитров ур., 34.

### *Алмаштырабыз*

**Норлаттагы 2 бүлмәле фатирны - Тольяттида 2 бүлмәлегә яки Тольяттида һәм Норлатта берәр бүлмәлеләргә.** Адрес: Советская ур., 183 - 12.

### *Ритуаль хезмәтләр*

**Мәрмәрдән кабер ташлары, төрле зурлыктагы тимер чардуганнар. 2 - 3 көндә ясап бирәбез, бәясе килешү буенча.**

**Шулай ук 2 япьле газ горелкалары сатабыз.** Адрес: Ленинградская ур., 14, тел.: 2 - 22 - 29.

Биккол урта мәктәбе укытучылар коллективы энесе **Альфредның** вакытсыз үлүе сәбәпле, укытучы Гөлфия Әнвәр кызы Сираҗеваның тирән кайгысын уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2071 данә. Заказ № 5742